ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 29 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында инновация эшчәнлеге турында» 2010 елның 2 августындагы 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 8 – 9; 2012, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 22 (I өлеш); 2019, № 40 (I өлеш); 2020, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 81 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Татарстан Республикасы инновация сәясәтенең максатларын, бурычларын һәм принципларын билгели, инновация эшчәнлегенә дәүләт ярдәме чараларын билгеләүгә һәм гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне, шул исәптән Татарстан Республикасында кече технологик компанияләргә дәүләт ярдәмен тормышка ашыру үзенчәлекләрен, җайга сала.»;

2) 2 статьяда:
а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:
«12) кече технологик компания – продукция эшләү һәм (яисә) җитештерү (хезмәтләр күрсәтү, эшләр башкару) эшчәнлеген инновация технологияләреннән файдаланып гамәлгә ашыра, «Россия Федерациясендә технологик компанияләрне үстерү турында» 2023 елның 4 августындагы 478-ФЗ номерлы Федераль законның 5 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән шартларга туры килә торган һәм кече технологик компанияләр реестрына белешмәләр кертелгән Россия коммерциячел оешмасы.»;

б) 2 өлештә «Фән һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте турында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба – Федераль закон)» сүзләрен «Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында» сүзләренә алмаштырырга;

3) 14 статьяда:

а) исемдә «төп таләпләр» сүзләрен «таләпләр» сүзенә алмаштырырга;

б) беренче абзацта «Дәүләт ярдәменә» сүзләрен «1. Дәүләт ярдәменә» сүзләренә алмаштырырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 2 өлеш өстәргә:

«2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан дәүләт ярдәменә дәгъва белдерә торган инновация проектларына башка таләпләр дә билгеләнергә мөмкин.»;

4) 15 статьяда:

а) 2 өлештә «әлеге Законда каралган таләпләргә» сүзләрен «әлеге Законның 14 статьясында каралган таләпләргә» сүзләренә алмаштырырга;

б) 3 өлештә:

1 пунктта «эшчәнлек төренең» сүзләреннән соң «Фән һәм дәүләт фәнни-техник сәясәте турында» 1996 елның 23 августындагы 127-ФЗ номерлы» сүзләрен өстәргә;

2 пунктта «әлеге Законның 14 статьясы таләпләренә» сүзләрен «әлеге Законның 14 статьясында каралган таләпләргә» сүзләренә алмаштырырга;

5) 18 статьяның 1 өлешендәге җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән башка рәвешләр.»;

6) түбәндәге эчтәлекле $18^1$ статья өстәргә:

«$18^1$ статья. **Кече технологик компанияләргә дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыру үзенчәлекләре**

1. Кече технологик компанияләргә дәүләт ярдәме Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан, шулай ук мондый ярдәмне гамәлгә ашыру мөмкинлеге булган тиешле оешмалар аша «Россия Федерациясендә технологик компанияләрне үстерү турында» 2023 елның 4 августындагы 478-ФЗ номерлы Федераль законда һәм әлеге Законда каралган рәвешләрдә тормышка ашырыла.

2. Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә салымнар түләү буенча ташламалар бирү рәвешендәге һәм (яисә) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанс ярдәме рәвешендәге дәүләт ярдәменә дәгъва белдерүче кече технологик компания үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырырга һәм салымнарны Татарстан Республикасы бюджетына түләргә тиеш.

3. Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары белән кече технологик компанияләргә дәүләт ярдәмен гамәлгә ашыруның башка үзенчәлекләре дә билгеләнергә мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 11 ноябрь
№ 77-ТРЗ